Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

17.02.2021 Менделеевск ш. № 96

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештыру турында

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең һәм Менделеевск муниципаль районының 2021 елның 28 гыйнварыннан 2.1-21/41 номерлы мәгълүмати хезмәттәшлеге буенча Килешүне тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

2. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, ТОСЭР һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарына 2021 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 07 августындагы 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә һәм дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең, мәгълүматлаштыру һәм элемтә Министрлыгының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга гариза җибәрүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, ТОСЭР һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.А.Абдуллин

Килештерелде:
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева